ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «17» августыннан № 327

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру тәртибен раслау турында»2016 елның 31 августындагы 349 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законынын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру тәртибен раслау турында» 2016 елның 31 августындагы 349 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлектә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Даими пассажирлар йөртүнең муниципаль маршруты әлеге маршрутлар турында Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 1 – 11 пунктларында каралган даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрутлары Реестрларына кертелгән көннән алып, әлеге Федераль законның 26 статьясындагы 1 өлешенең 3 – 11 пунктларында каралган үзгәрешләр кертелгән көннән башлап билгеләнгән яисә үзгәртелгән дип санала.»;

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әгәр дә азрак вакытлар даими пассажирлар йөртүне муниципаль маршрут буенча гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән пассажирлар йөртүчеләр белән килешелмәсә, мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында Башкарма комитет инициативасы буенча тиешле маршрутны үзгәртү яисә юкка чыгару турында карар мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланганчы йөз сиксән көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң үз көченә керә.

Башкарма комитет тарафыннан даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрутын үзгәртү турында карар кабул ителгәннән соң алтмыш көн эчендә әлеге маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелгән пассажирлар йөртүчеләр, кабул ителгән карар нигезендә, мондый таныклыкларның һәм әлеге маршрутларның карталарының гамәлдә булуын озайту турында гариза белән Башкарма комитетка мөрәҗәгать итәргә тиешләр.»;

2) 4 бүлекнең 3 пунктында «даими пассажирлар йөртү» сүзләреннән соң «(индивидуаль эшкуарның яшәү урыны турында белешмәләрдән тыш)» сүзләрен өстәргә.;

3) 5 бүлекнең 2 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;

4) 6 бүлекнең 4 пунктында «тиешле контрактны үтәү өчен кирәкле транспорт чараларының максималь саны нигезендә» сүзләрен төшереп калдырырга;

5) 7 бүлекнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрут картасы тиешле маршрут буенча даими пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган һәр транспорт чарасы өчен бирелә.»;

6) 8 бүлектә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бирергә:

«3. Ачык конкурс үткәрмичә, даими маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут картасы даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен түбәндә билгеләнгән очракта бирелә:

1) Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә, яки 29 статьясындагы 1 өлешенең 1, 2 яки 7 пунктында каралган шартлар җиткәннән соң һәм ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы яңа таныклык нигезендә даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлаганчыга кадәр. Федераль законның 24 статьясындагы 10 өлешендә каралган шартлар буенча даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм әлеге маршрут карталарын бирү үткәрелмәгән дип танылган ачык конкурста җиңүчегә рөхсәт ителми;

2) гадәттән тыш хәл шартларында халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне тәэмин итү максатларында билгеләнгән даими пассажирлар йөртү маршруты буенча.

Даими пассажирлар йөртүне муниципаль маршрут буенча гамәлгә ашыру турында таныклыклар һәм тиешле маршрутлар карталары пассажирлар йөртүчеләргә әлеге пунктта каралган очракларда ачык конкурс уздырмыйча, Башкарма комитетның муниципаль норматив хокукый актында билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән тәртиптә бирелә»;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ачык конкурс үткәрмичә, даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими пассажирлар йөртү маршруты картасы аларны бирү өчен нигез булган шартлар җиткән көнне, бер тапкыр, йөз сиксән көннән дә артмаган срокка, ә мондый хәл әлеге маршрут

буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында элегрәк бирелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып торган очракта, күрсәтелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору срогына бирелә.»;

7) 10 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10 бүлек. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның һәм даими пассажирлар йөртү маршрутының карталарының гамәлдә булуын туктату яисә туктатып тору

1. Башкарма комитет даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуын түбәндәге шартларның берсе булса да туктата:

1) әлеге таныклыкны биргән ташучыларның лицензиясен юкка чыгару турында суд карарының законлы көченә керүе;

2) әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында суд карарының законлы көченә керүе;

3) әлеге таныклыкны биргән пассажир ташучыларның таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән мөрәҗәгате;

4) әлеге таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамлану;

5) җайга салынмаулы тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне туктату һәм җайга салынулы тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлау турында Федераль законның 18 статьясында каралган карарның үз көченә керүе;

6) гадәттән тыш хәл булмаган очракта, өч көннән артык вакыт эчендә расписаниедә каралган бер генә рейс та башкарылмаса, тиешле маршрут буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык гамәлен туктату турында Башкарма комитет тарафыннан карар кабул ителү.

2. Әлеге бүлекнең 1 пунктындагы 1, 2, 4, 5 һәм 6 пунктчаларында каралган шартлар буенча даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуы әлеге шартлар килеп чыккан мизгелдән туктатыла.

Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән таныклыкларның даими пассажирлар йөртү маршрутларының бер лоты составына кертелгән берничә кешегә карата гамәлдә булуы шундый таныклыкларның берсен генә булса да гамәлдә булуы туктатылган очракта туктатыла.

3. Әлеге бүлекнең 1 пунктындагы 3 пунктчасында каралган шартлар буенча даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуы әлеге таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза кергән көннән туксан көн узгач туктатыла. Күрсәтелгән вакыт тәмамланганчы, мондый гариза белән мөрәҗәгать иткән пассажирлар йөртүчеләр әлеге таныклыкта каралган даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашырырга бурычлы.

4. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән пассажирлар йөртүчеләр Башкарма комитетка даими пассажирлар йөртү маршруты буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлаганнан соң утыз көннән дә соңга калмыйча аның гамәлдә булуын туктату турында язма рәвештә гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Башкарма комитет «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында (https://novosheshminsk.tatarstan.ru) күрсәтелгән гариза кергән көннән соң ун көн эчендә гариза керү турында мәгълүмат урнаштыра. .

5. Башкарма комитет түбәндәге шартларның берсе генә булса да килеп туган очракта, даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуын туктату турында гариза белән судка мөрәҗәгать итә:

1) Федераль законның 37 статьясындагы 2 өлешендә каралган срокларда, даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручының бер ел дәвамында берничә тапкыр даими пассажирлар йөртү маршруты буенча квартал саен хисаплар тапшырмавы.;

2) әлеге таныклык бирелгән пассажир йөртүченең административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 11.33 статьясындагы 4 һәм 5 өлешләрендә күрсәтелгән административ хокук бозулар турында административ хокук бозуларны кылган өчен административ җаваплылыкка тартылуы;

3) гади ширкәт шартнамәсен өзү (әлеге таныклык гади ширкәт килешүендә катнашучыларга бирелгән очракта);

4) пассажир йөртүче тарафыннан даими пассажирлар йөртү маршрутын үзгәртү турында Федераль законның 4 статьясындагы 15 өлешендә каралган очракларда һәм срокларда гариза тапшырмау;;

5) «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль законны гамәлгә ашыру хакында»2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законында каралган башка шартлар.

6. Даими пассажирлар йөртү маршруты карталарының гамәлдә булуы әлеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы туктатылган көннән, ә даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципаль контракт нигезендә гамәлгә ашырылса, әлеге контрактның гамәлдә булуы туктатылган көннән соң туктатыла .

7. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыкның гамәлдә булуы, җайга салынмый торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру өчен бирелгән даими пассажирлар йөртү маршрутының карталары гамәлдә булуы пассажирлар йөртүчедә (шул исәптән гади ширкәттә катнашучыларның берсендә генә булса да) автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булуы туктатылган очракта туктатыла.

8. Даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы таныклыкның гамәлдә булуы әлеге бүлекнең 1 пунктындагы 2 яки 6 пунктчасында каралган нигезләр буенча туктатылган очракта, әлеге

таныклык бирелгән пассажирлар йөртүчеләр аның гамәлдә булуы туктатылган көннән бер ел эчендә ачык конкурсларда катнашу хокукын югалта.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http:/ www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов